РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 20 мае № 35

Түбән Кама шәһәрендә муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелә торган өстәмә ташламалар исемлеге турында

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р һәм 821-р номерлы боерыклары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта нигезендә күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен өстәмә ташламалар исемлеген расларга.
2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр
Советының
2020 елның 20 маендагы
35 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама шәһәрендә күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен өстәмә ташламалар исемлеге

1. Арендага алучылар – кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне дәвамында арендага бирүче белән арендага алучы 2020 елның апрель-мае өчен мондый арендага алучылар тарафыннан тәкъдим ителгән вакытка кичектерелгән аренда түләүләрен 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча түли башлау срогы белән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү төзи.

Әлеге пункт нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель – июнь айларында аренда түләвен кичектереп торуны һәм аны тигез өлешләрдә 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда шартнамәсендә каралган срокларда түләүне, шулай ук аренда шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә, кичектерү бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның 1 гыйнварына аренда түләүләре түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаган арендага алучыларга – кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен кичектереп тору бирелә.

2. Авиапассажирлар йөртү өлкәсендә, аэропорт эшчәнлегендә, автомобиль белән ташу, мәдәният, ял оештыру һәм күңел ачу, физкультура-сәламәтләндерү эшчәнлеге һәм спорт, туристик хезмәт күрсәтү, кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы, өстәмә белем бирү, дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениеләре, конференцияләр һәм күргәзмәләр оештыру буенча эшчәнлек, халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (ремонт, юу, химчистарту, чәчтарашханә һәм матурлык салоннары хезмәтләре) өлкәләрендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы арендага алучылар – кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары аренда түләүләреннән азат итү таләбе белән муниципаль мөлкәт арендаторына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Аредага алучылар әлеге исемлекнең 2 пунктындагы 1 абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне дәвамында, арендага бирүче 2020 елның апрель-май айлары өчен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләреннән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешү төзи. Әгәр аренда килешүендә, аны әлеге исемлекнең 2 пунктындагы 1 абзацында күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралса һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне файдалануны раслаучы документлар булса, күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү гамәлгә ашырыла.

Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү әлеге карарның 2 пунктындагы 1 абзацында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның 1 гыйнварына аренда түләүләре түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаган арендага алучыларга карата гамәлгә ашырыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

Э.Р. Долотказина